Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Пестречинского
муниципального района
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль
районы
башкарма комитеты
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

«24» гыйнвар, 2023 ел № 32

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж алып баруны яңа редакциядә оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында»2019 елның 6 апрелендәге 217 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 21 декабрендәге 459-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 25 июлендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 06 февралендәге 217 номерлы карарына туры китерү максатларында Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 06 февралендәге 217 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 8.3 пунктында «ачык конкурс» сүзләреннән соң «даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына» сүзләрен өстәргә.»;

- 5.1 пунктына «яисә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең региональ комплекслы планы» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 абзацы 2024 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.Р. Байгильдинга йөкләргә.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе В.И. Никитин